СОВЕТ КУГУШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**27 июль 2026 ел** Күгеш авылы **№44**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районының Күгеш авыл җирлеге Советы нигезендә карар **кабул итте**:

1. Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга:

- «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Айдар авылындагы мәчет янында парковка кору.

2. Күгеш авыл җирлеге башкарма комитетына җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә, шулай

ук Күгеш авыл җирлегенең Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1а йорт адресы буенча мәгълүмат стендларында (хакимият бинасы) урнаштырырга.

**Күгеш авыл җирлеге башлыгы** **А.А.Гатауллин**